**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ярәп авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

**10 апрель 2024 ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 10 апрелендә узган: «2024 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Ярәп авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, бачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан, ялгыз яшәүче 85тән өлкәнрәк гражданнардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Ярәп авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 206 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 121 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 116 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 5 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ярәп авылы гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Ярәп авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, бачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан, ялгыз яшәүче 85тән өлкәнрәк гражданнардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Ярәп авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлегенең Ярәп авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Г.Н. Лизратова

Әхмәт авыл җирлеге башлыгы: Г.Н. Лизратова